
**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22



**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның «29» декабреннән

№ 5-32

«Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль милкендәге муниципаль мөлкәтне концессиягә тапшыру тәртибе турында» 2015 елның 25 декабрендәге 6-16 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 432-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 25 декабрендәге 6-16 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милкендәге муниципаль мөлкәтне концессиягә тапшыру тәртибе турындагы нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2016 елның 20 апрелендәге 12-53 номерлы карары редакциясендә) (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә:

«Концессия килешүе, Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, электрон формада төзелә.».

2. Әлеге карар 2027 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара эшчәнлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А. Тарнавский